Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино
авыл җирлеге Олы Бутырка торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

29 ноябрь, 2022 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Олы Бутырка торак пункты гражданнарының 2022 елның 29 ноябрендәге җыены беркетмәсе нигезендә түбәндәгеләр ачыкланды:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм гражданнар җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 159 (йөз илле тугыз).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны 81 (сиксән бер).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 74 (җитмеш дүрт).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 7 (җиде).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча « Сез 2023 елда Олы Бутырка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларын, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау»

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Ленино-Кокушкино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башлыгы А.Р. Сәйфетдинов